**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы**
**Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор авылы торак пунктында**
**2026 елда үзара салым акчасын кертү буенча**
**халык җыены КАРАРЫ**

2025 елның 14 нче ноябре № 2

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2025 елның 20 мартындагы N 33-ФЗ Федераль законның 45 һәм 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор торак пунктында халык җыены КАРАР бирде:

1. Үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан,балачактан инвалидлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, ялгыз өлкән пенсионерлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Ю.Гагарин һәм М.Җәлил урамнарына асфальт җәю);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгы коймаларын ремонтлау өчен буяу материаллары сатып алу);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (агачларны кисү).

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында,Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Х.Салихҗанов